ТАТАРСТАН
ВЕТЕРАНЫ
ВТ

№ 5–6
13 апрель, 2022 ел

РЕСПУБЛИКА ВЕТЕРАННАРЫ (ПЕНСИОНЕРЛАРЫ) ТӨБӘК ИҖТИМАГЫЙ ОЕШМАСЫ СОВЕТЫ ҺӘМ «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» ГАЗЕТАСЫНЫҢ УРТАК КУШЫМТАСЫ

«БАЛКЫШ» МИЗГЕЛЛӘРЕ
> 4-5

БЕР ЙӨРӘКТӘ – БИШ ХӘСРӘТ
> 6

«УФАЛЛА» АРБАЛАРЫ
> 7

ӘШЛӘП КЕНӘ ТОРЫР ИДЕ...

Апас районының Морзалар авылында яшәүче Әминә әби Латыйпова 101 яшьлек гомер бәйрәмен көр күңел, күтәренке кәеф белән каршы алды. Күзләр тимәсен, ул бүген дә җитез, хәтере шәп, тормышның һәр мизгеленнән шатлык табып яши белә. Әле сыналган орлыкларыннан тәрәзә төбен тутырып үсентеләр утырткан. Помидор, борыч үсентеләренең матур гына үсеп китүләренә сөенә.

Ачлы-туклы үткән балачак, авыр хезмәткә җигелеп үткән яшьлек еллары, ачы сугыш хәсрәтләре Әминә әбинең күңелендә тирән яралар калдырган, шул ук вакытта аны нык иткән, кырыс җилләргә каршы торырлык көч өстәгән.

– Хезмәтне яраттым. Тырыш булдым. 15 яшемнән ат җигеп, колхозда эшләдем. Сугыш башлангач, атларны, тракторларны фронтка озатып бетергәч, үзебез ат та, трактор да булдык. Ат булып җигелмәдем, әмма ат кебек эшләдем, – ди әби.

Әминә әби һәр эшнең үзәгендә булган. Икмәк чыгару, урман кисеп, утын әзерләү, окоп эшләре үзәгенә үткән. Тыныч тормышта да намус белән, җиренә җиткереп хезмәт иткән. Кошчылык фабрикасында, колхозның төрле эшләрендә җиң сызганып үз көчен куйган.

– Хезмәт белән сыналып, алабута икмәге ашап үскән буын без. Гел хәрәкәттә булуның да сәламәтлеккә йогынтысы уңай булгандыр. Бүгенге тормышны күрү – зур сөенеч, – ди әби.

Әминә әби гомер буе чисталык, пөхтәлек яраткан. Бакча тутырып яшелчәсен үстергән. Күпләргә мул уңыш үстерү серләрен өйрәткән.

> 3

Яңалыклар

Ни хәлегез бар?

Буа муниципаль районында ялгыз яшәүче 80 яшьлек һәм аннан да өлкәнрәк кешеләрнең өйләренә барып, хәлләрен белешү дәвам итә. Быел «Гармония» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплексы үзәге белгечләре районда яшәүче 375 пенсионер белән очрашкан. 80 яшьтән өлкән булган 13 кешегә өйгә барып социаль хезмәт күрсәтү кирәклеге ачыкланган. Хәл белешүчеләр өлкәннәр белән янгынны кисәтү турында сөйләшә, ашыгыч ярдәм күрсәтүче хезмәтләрнең телефоннарын калдырып китә.

Матур бәйрәм

Әлмәттә яшәүче Газимә Натфулла кызы Гатина 95 яшьлек юбилеен билгеләп үтте. Аны котларга район башлыгы Тимур Нагуманов һәм район ветераннар советы рәисе Владимир Яшанин килде.

Газимә Гатина 1927 елның 29 мартында Алексеевск районының Урманасты Шенталасында туган. Гаиләдә 9 бала тәрбияләнә. Әтисе колхозда эшли, әнисе балалар тәрбияләү белән шөгыльләнә. «4 сыйныфны тәмамладым да колхозда эшли башладым», – ди ветеран.

Сугыш тәмамланганнан соң мәктәптә укуын Биләрдә дәвам итә ул. 7 сыйныфны тәмамлагач, хастаханәгә эшкә урнаша. 1951 елда кияүгә чыга һәм 4 бала таба. Фидакарь хезмәте өчен бик күп медальләр һәм рәхмәт хатлары белән бүләкләнгән. Бүген ул – 9 онык һәм 13 оныкчыкның әбисе.

ҖАНГА РӘХӘТ ЭШ

Шөгыль

«Бал кортының балы бар, балга кадәр назы бар» дигән әйтемне беләсезме? Чинчурино авылыннан Григорий Приказчиков әлеге сүзләрнең хаклыгына башкалардан күбрәк ышанадыр диясе килә. Нәселдән килгән умартачыга кунакка мартның җылы бер көнендә бардык һәм ул, без килгәндә, якты кояш нурларында җылынып, алда торган, эшмәшәкатьләр турында уйланып, йорты каршындагы эскәмиядә утыра иде.

Григорий Ивановичка – 85 яшь. Чинчуринода туган, Тәтештә – унъеллыкны, Куйбышевта (хәзерге Самара) инженер-төзелеш институтын тәмамлаган. Ульяновскида инженер-төзүче булып, аннары проект институтында эшләгән. 1990 нчы еллар башында, пенсиягә чыккач, ата-анасы йортына кайткан.

– Әле 1978 елда ук, төзүче һөнәрен проект белгечлегенә алыштырганда, Ульяновскидан Чинчуринога ешрак кайту мөмкинлеге барлыкка килде. Әтием умартачы иде. 1931 елда аны Казанга квалификация күтәрү курсларына җибәрделәр, аны тәмамлаганнан соң, умартачылык буенча инструктор булып эшләде, бөтен районга хезмәт күрсәтте. Анннары колхоз умарталыгында умартачы булды. Үзенекен карагач, иртән янә колхоз умарталыгына китә. Шуны күреп үскәч, мин дә кечкенә чакта балчыктан «өй» төзеп, анда тишек ясавымны хәтерлим. Бал кортларын тотам да шунда салам, тик алар анда яшәп китә алмадылар, – дип көлеп искә ала умартачы.

Григорий Иванович Чинчуринога кайтып төпләнгәндә, әтисе умарталыгыннан бер умарта калган була, аның белән әнисе һәм әбисе шөгыльләнгән. Вакытлар узу белән умарта гаиләсенең исәбен ул 60ка кадәр арттырган.

– Умарта ояларын һәм кысаларны үзем ясарга өйрәндем. Башта әтидән калганнарны кулландым. Кысалы умарта ояларын ничек ясарга икәнлеген белә идем инде. Ә 70–80 нче елларда алар белән эшләүнең башка системасы барлыкка килде: магазиннар (автор искәрмәсе: бал кортлары бал җыю өчен билгеләнгән умарта корпусының бер өлеше) түгел, ә икенче корпуслар куелды. Умарта кортлары һәм бал күләме артты, бал кортлары аерылып чыгу азайды. Ул чакларда юкә чәчәк атканда балны берничә тапкыр алдык. Хәзер алай түгел. Экология начар. Умарта гаиләләре зәгыйфьләнә төште. Ул чакта талпан да юк иде, алар шулай ук бал кортларын зәгыйфьләндерә, – дип сөйләвен дәвам итә Григорий Иванович.

Җылытып эшкәртүне ул талпанга каршы иң нәтиҗәле ысул дип саный, шуңа күрә үзе җылылык камерасы ясаган. Журналларда язылганнарны укыган, инженерлык белеме дә, проект институтында эшләү тәҗрибәсе дә ярдәм иткән. Бал кортларын дәвалау өчен аның уйлап тапканнарын хәзер уллары да куллана, алар – шулай ук умартачылар.

– Бал кортлары мине чакмый. Хәзер карпат токымлыларны яки кушылганнарны тотам. Алар тыныч. Әтидән урта рус токымлы умарта корты гаиләсе калды. Менә ул чага иде! Бигрәк тә бал алганда, – ди Григорий Иванович, елмаеп, һәм безгә бакча буйлап экскурсия уздыра. Бирегә кар өеме астында тәрле төстәге умарта оялары яшеренгән, ә аларда инде тормыш җанлана: меңнәрчә бал корты алтынсу кәрәзләрне куе, хуш исле бал белән тутыру өчен үз сәгатен көтә.

Елена КАЛАШНИКОВА.
Тәтеш районы

«ӘТИ» ДИП ӘЙТЕРГӘ ТИЛМЕРДЕК

Шушы көннәрдә Кукмара районының Сазтамак авылындагы 87 яшьлек Нәзирә Закирова белән таныштык. Балачагы, үсмер вакытлары бик авыр чорларга туры килгән аның.

– Әти сугышка киткәндә, миңа биш яшь иде. Безнең, дүрт баланың, башыбыздан сыйпады, кара кайгыга баткан әниебезне кочагына кысты да өй турыннан узып баручы башка ирләргә кушылды. Әни соңгы сулышына кадәр аның исән-сау әйләнеп кайтуын көтте. Әмма юкка булды шул... Без гомер буе «әти» сүзен әйтергә тилмереп, әтиле балаларга кызыгып яшәдек, – ди ул.

Мәктәптә укыганда колхоз басуында башак җыюларын, кеше күрмәгәндә генә кесәсенә салып, өйгә алып кайткан бер уч арышны уып, шуннан аш пешергәннәрен дә күз яшьләрсез искә төшерә алмый Нәзирә апа. Болынлыктан торф ташу, сыер тизәген, кирпеч сыман итеп катырып, мичкә ягулар, чалгы белән колхоз басуында печән, борчак чабулары, бригадир булып эшләгән вакытлары да онытылырлыкмы соң?!

20 яшендә авылның иң чибәр, булдыклы Рафаэль исемле егетенә кияүгә чыкканын искә төшергәндә, күзләре аеруча ялкынланып янды әбинең. Өч малай, бер кызга гомер бирә бәхетле пар.

– Авыл фермасы янганнан соң, болында тораклар ясап, мал-туарларны шунда күчерделәр. Мин анда иң элек ат карадым, соңыннан дуңгыз балалатуда эшләдем һәм шуннан пенсиягә чыктым. Иптәшем колхозда төрле эшләрдә хезмәт куйды. Безнең беркайчан өйдә утырырга вакыт булмады, эш тә эш... Фермадан кайтуга, үзебезнең хуҗалыктагыларын карарга керешә идек. Сыерларыбыз да өчтән ким булмады. Бозаулар, сарык, тавык-чебешнең исәбе юк. Ирем үлгәч тә, малларны бетермәдем, кешедән ким-хур булмыйм дип тырыша идем. Балалар да ярдәм итте. Шөкер, улларым да, кызым да акыллы, тәүфыйклы булдылар, йөзгә кызыллык китермәделәр. Миннерахман – Венгриядә, Рәшит – Латвиядә, ә инде Азат Германиядә хезмәт иттеләр. Бердәнбер кызым Кадрия дә нәрсәгә тотынса, шуны башкарып чыга иде. Хәзер дә үзгәрмәде, җиңен сызганып куя да кирәк икән – бакчасын казып чыга, кирәк икән – сыерын сава... – ди ул.

– Безне эшкә дә, олыны – олы, кечене кече итәргә дә өйрәтте. Тиздән миңа 60 тула. Бу яшькә кадәр әниле булуым белән бик бәхетлемен. Авырып китсә, йокым йокы түгел. Яши генә күрсен иде әле, – ди кызы Кадрия.

48 ел каенана белән яшәгән Нәзирәападан озын гомерлелекнең серен дә сорамый кала алмадык. «Әни белән беркайчан сүзгә килгәнем булмады, бар эшне бергәләп башкардык. Оныкларыма, оныкчыкларыма да: «Шөкер итә белергә өйрәнегез. Гаилә коргач, ирегезнең әти-әнисен рәнҗетмәгез, кыерсытмагыз», – дип әйтә киләм. Чөнки өлкәннәрнең хәер-фатыйхасын алган кеше бик бәхетле һәм озын гомерле була», – ди җиде онык, унбер оныкчык әбисе.

Нәзирә әбинең оныгы менә нинди матур хатирәләр белән бүлешә.

– Миңа ул чагында җиде-сигез яшьләр тирәсе булгандыр. Әни тегеп биргән кечкенә сумкага салып, көн саен күрше урамда яшәүче әбиемнән сөт алып кайта идем. Берсендә як-якка болгый торгач, ташка тиеп китте дә, банкам урталай ярылды, сөт исә тамчысына кадәр агып бетте. Инде нишлим икән дип, елар дәрәҗәгә җитеп, куркуымнан калтырый-калтырый, кире борылдым. Әбинең мине ничек итеп ачулануын күз алдына китереп, әкрен генә капкадан керүем бүгенгедәй хәтердә, – ди Эльвира. – Бәхеткә, борчылуым юкка булды. Иелгән башымны, яшь белән мөлдерәп тулган күзләремне күргән әби: «Бер дә кайгырма, кызым, банка бетмәгән ул», – дип, мине кочагына алды. Әбием һәрвакыт минем яклы булды, хәзер дә барлык серләремне аның белән бүлешәм, төпле киңәшләре авыр вакытларымда дөрес юл сайларга ярдәм итә.

Әңгәмәдәшем хәзерге көндә төпчек улы Азат абый гаиләсендә яши. Колаклары ишетә, күзлексез күрә, зиһене яхшы, биш вакыт намазын калдырмый, ил-көн яңалыкларыннан хәбәрдар ул.

– Газетаның, дини китапларның бер җөмләсен дә калдырмый укыйм, телевизор да карыйм. Тормышыма шөкер итеп яшим. Бигрәк рәхәт бит дөньялар. Илләр тыныч булсын, киләчәк буын тыныч тормышта яшәсен иде, – ди ул.

Алсу СӘЛАХЕТДИНОВА

ҺӨНӘР ОСТАСЫ – ИЛ ТОТКАСЫ

Тимерчеләр нәселеннән

Үзенең яшәгән табигатенә охшаш буладыр ул авыл кешесе. Әнә Әгерне чишмәләр җире дип әйтүгә, шундый ук саф күңелле кешеләре янына тартыла башлыйсың.

– Бөтен тормыш агышыбыз да шул чишмәләребез агышы кебек саф инде безнең, – дип тикмәгә әйтмидер бөтен хезмәтен ипекәй үстерүгә биргән мөхтәрәм игенче, техника остасы Марсель Гәрәев. – Бу һөнәр агышы да нәкъ шулай: әтиләр өйрәтә, без – уллары – дәвамчылары. Әиген үстерү бик тырышлык, сабырлык, түземлек һәм барысыннан да элек кешелекле, ярдәмчел, бердәм булуны сорый. Минем әткәй нәкъ шундый: үзеннән бигрәк башкаларны кайгыртучы иде.

Әйе, әтисе Дәүҗәт абый тимердән чәчәк коя торган оста куллы тимерче иде, ягъни шундый нәселдән. Техника куәтенең мондый чагында бу һөнәрне, әлбәттә, шул кимәлдә бәяләмичә мөмкин булмагандыр да. Сабан дисеңме, чәчкеч, культиватор, тырмамы – барысы да тимерче кулы аша үтә торган вакытлар ул. Кемнең генә аңа йомыш-гозере төшмәгән! Дәүҗәт абый – моның өстенә бик чос эретеп ябыштыручы да. Т-40 тракторына менә дә ватык-көйсез дигәннәрен сафка бастырырга ашыга. Ул – заманы өчен иң кирәкле оста, белгеч! Җитмеш яшен түгәрәкләгәндә дә шул утлы тимерне ябыштырып йөри, хөрмәтле һөнәреннән ямь-тәм табып яши. Бу җәһәттән өч малае да, аерата төпчеге Марсель, һич артырып әйтү булмас, тәпи атлаганда ук тотам да калмый. Ни өчен дисәң, авылда балалар бакчасы юк, әнисе Миңнур апа таңнан фермага бозау караргa китә, кая калдырсын – почык борыннарның көннәре тимерче алачыгында әтиләренә тегесен-монысын алып биреп үтә.

– Бишенче класстан соң каникулда бригадир Миргаяз абый, кызу урак барганда, мине «КамАЗ»га грузчик итеп алып китте, уку башланганчы комбайн

vk.com

бункерыннан ашлык ташыдык, – дип искә ала ул. – Алдагы елны да әти «по блату» Исхаков Сәгадәт абый белән комбайнчы ярдәмчесе итеп мине алу турында сөйләште. Анда тәртип шулай: иртән үк иң алдан комбайнны бик өлгер майлап чыгу. Шулай өйрәнмәсәм, профтехучилищеда укыганда ук, иске генә СКД-6 комбайнына утыртмаслар иде мине. Аннары җитмешне үткән әткәй урынында – тимерчелектә нәсел һөнәрен дәвам иттердем.

Ә бүген инде үзе күпләрнең остазы – өйрәтүчесе ул, «безнең Марсель» дип, аерым якын-үз итеп эндәшәләр. Кайберәүләр кебек күзеңә керә торган түгел үзе, тыныч-басынкы характерлы, нәрсәгә тотынса да, ахырынача бик төгәл башкарыр. Хәер, авыл кешесенең, кем әйтмешли, җитмеш төрле һөнәре булмаса, бөтен ихата-йортыңны җитешле алып бару мөмкин дә түгелдер инде. Нинди проблема туса да, Марсель белми-булдырмый калмас, дип гел аңа килүләр. Ул исә һичкайчан борын күтәреп йөрмәс, гомумән дә үзенне өстен кую – әгерлеләргә чит нәрсә.

– Әнә әтиебезнең бик якыны Бәгыйс абый Абдуллин вафатыннан соң 40 ел үткәч кенә, фотоларын актарганда ачыкланды: дөньяның беренче космонавты Юрий Гагарин белән бергә төшкән! Мәскәү янындагы хәрби частьта хезмәт иткәндә, аны «Звездный» космодромына шофер итеп башта «ЛАЗ» автобусына, аннары «Алга» машинасында Юрий Гагаринны йөртергә билгелиләр. Менә кемнең шоферы булган Бәгыйс абый – чын-чынлап горурланырлык! Сер итеп саклаган (әйтергә ярамагандыр инде), армиядән кайткач та безгә гел килә иде үзе.

Марсель анысы алай ук югарылыкта түгел түгелен, ләкин район күләмендә билгеле техника остасы, звено җитәкчесе, бригадир булып танылса да, үзен аерып тотмады. Заманында Никита Хрущев килгән «Авангард» колхозының шушы Әгер бригадасында шикәр чөгендерен үзе чәчеп, ашлап, карап үстереп, комбайн белән алып, районда иң алдынгы звено җитәкчесе була. Иң күп җир сөрүче, иң күп чәчүче – Сабан туенда кыр батыры исеменә лаек! Берүзенең кул астында – К-700, ДТ-75, Т-70, МТЗ-80 тракторлары, КС-6Б чөгендер алу, Дон-1500 ашлык суктыру комбайннары, туфрак эшкәртү, чәчү агрегатлары. Барысы да тезек: берсеннән төшә, икенчесенә утыра, гел хәрәкәттә!

Шул тиклем күнеккәннәр Марсель Гәрәевнең өлгер-булдыклы гадәтләренә: менә кирәк икән бүген, ул – бригадир, кирәк икән – инженер-техник. Хәзер дә элек ничә колхозны берләштергән Азнакай агрофирмасының Тымытык бүлекчәсендә баш инженер. Үзен хөрмәт итәләр, кушканын сүзсез тыңлыйлар, чөнки ул төгәл әйтә белә. Шуңа эше җайлап бара, бигрәк тә яшьләр белән дустанә мөгамәләдә: кыен чакта өйрәтеп җибәрер. Юкса кайбер җитәкчеләр бик аздан да яшь кадрны китеп барырлык хәлгә җиткерәләр. Эшли башлаган вакытларында үзенең дә андый хәлләр алдында калганы булмады түгел, булды. Әтисенең: «Үз сүзеңдә нык калырга кирәк, улым!» – дип әйткәне исенә төшеп, һич югалып калмый иде. Аның дистәләгән төрдәге техниканы теләсә кайсы вакытта иярли алуы да үз сүзендә нык торуыннан киләә. Хәзер элеккеге кебек техникага чат ябышып утыручылар да юк. Әнә «КамАЗ» тик тора, Марсель үзе утыра да җир җимертеп йөри. Кырыенда – бер яшь егет, үзе кебек ышанычлы һөнәрле дә итә аны!

Мал-туар асрауда да Марсельдән башка булмый – үзенең мал-туары, диетик күркә кебек кош-кортлары белән сыйлый. Күп сугымнар Марсельнең игелекле-җылы куллары аша башкарыла. Алагаем түшкәне ашка салырлык, бәлешкә турарлык итеп кисеп бирер: балта белән түгел, автокискеч ясаган.

Кыен замана, чирләп китсәң – кая барып хәл алырга? Менә шундый вакытта да Марсель ярдәмгә килә авылдашларына. Машинасына утыра да тәүлекнең теләсә кайсы чагында башкалабыз Казанга таныш табибларны янына юлга чыга һәм булдырып кайта – рәхмәтләрнең иң олысы аңа!

Әйе шул, Марсель кебек бөтен яклап килгән ялыкмас, булдыклы, кешелекле кешеләр булганда гына бүгенге авылга чын кадер иңә. Челтер чишмәләре ургып торган Әгер шундый тимерчеләр нәселен дәвам иттерүче ир-егетләре белән үзен данга күмә, киләчәккә ышанычлы адымнарын атлый.

Әсгать СӘГЫТДИНОВ.
Азнакай районы

Белдерү

Татарстан Республикасы ветераннарының (пенсионерларының) төбәк иҗтимагый оешмасы ветераннары республика советында техник реабилитация чараларын прокатка бирү пункты оештырылды

Техник реабилитация чаралары (алга таба – ТСР) вакытлыча файдалануга бушлай бирелә:

- физик мөмкинлекләре чикләнгән, индивидуаль реабилитация һәм абилитация программасына ия булмаган;

- авыр хәлдә калып (җәрәхәтләнү, каты авыру, операция кичерү сәбәпле), техник реабилитация чарасына вакытлыча мохтаҗ булган (инвалидлык рәсмиләштерү, ТСРга хокук алу чорына яки реабилитация һәм савыгу чорына);

- авыр хәрәкәтләнүче өлкәннәргә.

ТСР алу өчен Прокат пунктына түбәндәге адрес буенча мөрәҗәгать итәргә кирәк: Казан ш., Театр ур., 5 й., Татарстан Республикасы ветераннары (пенсионерлары) республика советы. Элемтәгә керү өчен телефон: 236-96-83.

Прокат пунктына ТСР алу өчен тапшырылырга тиешле документлар исемлеге:

ТСРны вакытлыча файдалануга бирү турында шәхсән гариза (гражданинның законлы вәкиленең гаризасы);

мөрәҗәгать итүченең шәхесен раслаучы документ күчермәсе;

мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиленең шәхесен раслаучы документ күчермәсе (документларны мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиле тапшырганда).

Техник реабилитация чараларын прокатка бирү пунктының эш графигы

Дүшәмбе	**9.30 сәгатьтән**	**15.30 сәгатькәчә**
Сишәмбе	**9.30 сәгатьтән**	**15.30 сәгатькәчә**
Чәршәмбе	**9.30 сәгатьтән**	**15.30 сәгатькәчә**
Пәнҗешәмбе	**9.30 сәгатьтән**	**15.30 сәгатькәчә**
Җомга	**9.30 сәгатьтән**	**15.30 сәгатькәчә**

Техник реабилитация чараларын прокатка бирү пунктындагы ТСР исемлеге

№ п/п	Техник реабилитация чаралары атамасы
1.	Бүлмәдә йөрү өчен кресло-коляска
2.	Урамда йөрү өчен кресло-коляска
3.	Терсәк таягы
4.	Алюминийдан ясалган култык таягы
5.	Таянып йөрү өчен җайланма (ходунок)
6.	Телескопик таяк
7.	Тәнне бозмый торган матрас
8.	Тоткычлы шума җәймә
9.	Алмаг-01 магнит терапиясе аппараты
10.	Скандинавча йөрү өчен таяклар

ЭШЛӘП КЕНӘ ТОРЫР ИДЕ...

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Кул эшләренә дә оста ул. Төннәрен дә тегү теккән. Балаларын, якыннарын, авылдашларын матур-матур киемнәр белән сөендергән.

Минһаҗ абый белән 65 ел тигез, тату гомер кичергән алар. Үз үрнәкләрендә акыллы, эш сөючән дүрт бала тәрбияләп үстереп, олы тормышка чыгарганнар. Тик, кызганыч, Минһаҗ абый 11 ел элек гүр иясе булган. Бүген Әминә әби кызы Рәйхана тәрбиясендә яши. Барлык балалары, оныклары да янына кайтып-килеп йөри.

– Әни һәрвакыт безнең өчен терәк булды. Хезмәт белән тәрбияләде. Тормышта да нык һәм көчле булырга өйрәтте. Олыгайган көнендә дә ул көчле рухлы булуы белән сокландыра, үрнәк булып тора. Без аның янына кайтып сыенабыз, аңардан көч-куәт алып китәбез. Аллага шөкер, сәламәтлеге дә әйбәт. Үз аякларында йөри. Барыбызны кайгыртып, тәртипкә салып тора, – ди улы Рифкать.

Әминә әбинең һәр көне балаларын, оныкларын, оныкчыкларын барлаудан, аларга изге теләкләр теләүдән башлана. Акъәби һәр мөһим вакыйганың да үзегендә булырга тырыша. Дини китапларны күзлексез генә укый, яраткан тегү шөгыленнән дә аерылмый.

– Тишелгән, сүтелгән кием-салым күрсә, инә-җебен ала да тегеп куя. Эшләп кенә торасы килә аның, – ди кызы Рәйхана апа.

Ләйлә ШИҺАБИЕВА

ӨЛКӘННӘР СӘХНӘ ТОТА

«БАЛКЫШ» VII РЕСПУБЛИКАКҮЛӘМ ФЕСТИВАЛЕНЕҢ РАЙОН ТУРЫ ГАЛА-КОНЦЕРТЫ ҮТТЕ

Быел фестиваль Татарстан Республикасы ветераннар төбәк иҗтимагый оешмасының 35 еллыгына багышлап үткәрелә.

– Дүрт ай буе авылларга йөреп, талантларны барладык. Җиде зонада 700дән артык кеше катнашты. 160 номер булды. Иң көчле 50 номерны сайлап алдык. 25е – Яңа Кенәр мәдәният йорты, калганнары Арча сәхнәсендә чыгыш ясый, – диде район ветераннар оешмасы рәисе Рәмзия Хәмидуллина. – Дүрт ай буе сезнең белән булдым. Шуны белдем: ветераннар арасында нинди генә талантлы шәхесләр юк икән! Сокланырлык, искиткеч чыгышлар. 50 номерны сайлап алу бик авыр булды. Хәзер шулар арасыннан да зона турына 10 номерны гына сайлап алырга кирәк була. Без яшибез, без яшь икән әле. Киләчәктә дә шулай дәвам итсен.

– Иҗатка булган мәхәббәтегез өчен рәхмәт. Тормыш авырлыкларына бирешмичә, иҗат белән бергә атлыйсыз, мәдәни мирасны халыкка тапшырасыз, – диде Арча районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Эльвира Вафина.

Концерт Курса-Почмак үзешчәннәре башкаруында фольклор күренеше белән башланып китте. Җыр-биюләр, уеннар күпләрне яшьлекләренә алып кайтты. Ә аннан инде залга җыр, моң агылды. Күбесе – тамашачылар яшь вакытларында башкарган көйләр. Шуңадыр, җырчыларга кушылып, эчтән генә булса да көйләп тә утыручылар булды.

Арчалылар игътибарына тәкъдим ителгән утыздан артык номерның һәрберсен иң матур сүзләр белән генә мактыйсы килә. Гөрләтеп кул чабалар икән, димәк, алар моңа лаек. Арча тамашачысы юкка гына алкышлар яудырмый.

«Туган якның төнге күге истә, һаман да истә». Әнә шулай чиста, көчле матур тавышы белән Миркәмнән Басыйр Шаяхмәтов үзе гармунда уйнап җыр сузды.

– 5 яшьтә гармунда уйный идем инде мин, – диде Басыйр. – Әтидән өйрәндем. Кенәбашта үстем мин. Мәктәптә укыганда да уйнадым, җырладым. Әтинең дә, әнинең дә тавышлары бик матур иде. Өстәвенә әни бии, әти гармунда уйный. Сәнгатькә мәхәббәт шулардан күчкәндер инде. 1978 елда авылдан чыгып киттем. Акчишмәдә урманчылыкта эшләдем. Урманда да, көтү көткәндә дә гел җырлый идем. Сәхнәләрдә чыгышлар ясадым. Озын көйләрне яратам мин. Ә бервакыт Марат Дәүләтшин мине Арчага чакырып алды. Менә шуннан китте. Фестивальләрдә беренче урыннарны яуладым, «Уйнагыз, гармуннар!»да катнаштым. Кыскасы, сәхнәдән төшкән юк.

Абыйлы-энеле Васыйл һәм Вагыйз Әһлиуллиннар гармунда өздерде генә. Вагыйз – мәдәният хезмәткәре, сәнгать сөючеләрдән аны кем генә белми икән. Абыйсы Васыйл да оста гармунчы икән бит!

– Безгә 9–11 яшьләр тирәсе иде. Әти гармун алып кайтты. Ярыша-ярыша өйрәндек. Клуб мөдире Абдулла Лотфуллин шуны күреп, клубка ике гармун алды. Безнең өчен. Хәтерлим әле: әтине утыртып, аның ике ягына басып гармун уйнадык. Әти шунда «Арча» җырын башкарды. 1971 ел иде ул. Беренче тапкыр сәхнәгә чыгуым шул булды. Абый гомер буе тракторда эшләде, әмма гармунын ташламады, сәхнәдән төшмәде, – ди Вагыйз.

Курса-Почмактан «Чишмә» вокаль ансамбле җырчылары шушы фестиваль өчен махсус бер төрле костюмнар сатып алганнар. Илдус авылыннан трио профессиональ артистлардан кимен куймады. Кызлар «Алмагачларым»ны башкардылар. Иң матур чыгышларның берсе булды ул. «Ә кайда әзерләнгәннәр?» – дип сорагыз. 20 хуҗалыклы авылда клуб та юк бит. Өйләрендә! Үзләрен шундый иркен тоталар, рәхәтләнеп, дөньяларын онытып җырлыйлар. Башлап җырлаучысы – «Ел хатын-кызы» бәйгесе җиңүчесе, күп бала анасы Гөлгенә Хәбибрахманова.

«Көн саен керәсең төшемә», – дип җырлады Иске Төрнәледән Тәлгать Бәдгыев. Аңа – 65 яшь. Гомере буе колхозда эшләгән. Соңгы 15 елда токарь булып. 10–12 яшьтә гармунда уйнарга өйрәнгән. 2 нче сыйныфта укыганда җырлый башлаган.

– Беренче җырымны 1944 елгы абыем армиядән ялга кайткач башкардым. Миңа ул чакта 6 яшь иде. Елга буена төшеп, «Кайтам инде туган ягыма»ны суздым, – ди Тәлгать. – Минем әнинең әтисе җырлаган. Ул революция вакытында ук үлгән. Әби шулай ди иде. Нәселдә башка җырчы юк. Шул бабайдан күчкәндер инде. «Сибелә чәчем» кебек озын җырларны яратам. Шатланганда да, борчылганда да, кәеф күтәренке булганда да сәгатьләр буе уйный алам.

– Минем әни белән әти җырлыйлар иде. Биш баладан үзем генә алар юлыннан киттем. Кечкенәдән җырлыйм. Миркәм, Пешәңгер клублары сәхнәләреннән төшмәдем. Шигырьләр дә язам. Мәктәптә укыганнан бирле. Лаеклы ялга чыккач, рәхәтләнеп яза башладым. Китап итеп бастырырга хыялланып йөрим. Бик күптәннән сәхнәгә чыккан юк иде инде, менә тәвәккәлләдем, – диде Лесхозда яшәүче Әлфия Каюмова.

Ул җырламый да кебек, иреннәре генә селкенә, ә күпме моң агыла. Шунда танылган җырчы Миңгол Галиевның бер очрашканда әйткән сүзләре искә төште: «Чын җырчы авызын зур итеп ачып кычкырып җырламый. Аның иреннәре арасыннан гына моң агыла». Әлфия ханым да йомшак матур тавышы белән әсир итте.

Биючеләр турында әйтми калу дөрес булмас. Чөнки алар ике бөртек һәм ниндиләр! Нурия Әхтәмова – башкорт, Тәнзилә Вәлиева үзбәк халкы биюен башкардылар.

Ул көнне өч сәгатькә якын барган концерт сизелми дә үтеп китте. Рәмзия Хәмидуллина әйткәнчә, сез яшь әле, яшь күңелле. Киләчәктә шулай сәнгать белән яшәү атлап, көнләшерлек итеп яшәгез.

29 мартта Арчада фестивальнең зона этабы үтте. Анда Арча, Әтнә, Теләче, Биектау, Балык Бистәсе районнары үзешчәннәре катнашты. Чыгышларга мәртәбәле жюри бәя бирде.

Гөлсинә ЗӘКИЕВА.
Арча районы

veterany.tatarstan.ru

ПОСВЯЩАЕТСЯ

СИЯНИЕ
Балкыш

БЕР ЙӨРӘКТӘ – БИШ ХӘСРӘТ

100 яшь – бу күпме, әллә азмы? Кемнәрдер өчен ул гаять зур булып тоелса, кем өчендер тормыш сукмагының бер өлеше генә. Биниһая зур, әмма шулай да бер өлеше.

Күптән түгел йөз яшен тутырган Алабакүл авылында яшәүче Әнвәрия Вахитова бүген дә хәрәкәттә, акылы аек, караваты янындагы киштәгә пөхтә итеп өеп куелган газета-журнал, китаплар укырга ярата, дөнья яңалыклары белән кызыксынып тора. Без килгәндә, ул күзлексез генә (!) якыннарының газета битләрендә аны котлап язган тәбрикләвен укый иде. Аның белән бик озак сөйләштек. Ул барысын да яхшы аңлый, һәр нәрсәне аек акыл аша бәяли. Гаҗәпләнүемнең чиге булмады!

Әнвәрия апа Баулы районының Кызылъяр авылында укытучы гаиләсендә төпчек бала булып дөньяга килгән. Озакламый гаилә башлыгы Салих Шакир улы Вахитовны Бәйрәкә мәктәбенә эшкә күчерәләр. Ул анда иң элек тарих фәненнән белем бирә, аннары мәктәп директоры вазыйфасын башкара. 1937 елда, төбәгебездә иң беренчеләрдән булып, Бәйрәкә мәктәбе урта мәктәп итеп үзгәртелә. 9 нчы сыйныфта укыганда, Әнвәрия Казаннан Бәйрәкә мәктәбенә эшкә юлланган яшь белгечкә – география укытучысына кияүгә чыга.

Кияүдә булганда, ул урта мәктәпне тәмамлый. Һәм хезмәт эшчәнлеген башлангыч сыйныф укытучысы буларак башлый. Бер-бер артлы кызы һәм улы туа. Ярый әле әнисе аның янәшәсендә була. Әнвәрия эштә вакытта ул балаларны карап тора. 1941 елда ире Варис үз теләге белән фронтка китә. Бу вакытта яшь әни өченче баласын көтә. Бераздан Әнвәриянең кызы дөньяга аваз сала. Бөек Ватан сугышы елларында аңа эшләргә дә, гаиләне туендырырга да туры килә. Ә нәрсә ашатырга соң? Көннәрдән беркөнне Әнвәриянең әнисе басуда калган бодай башакларын җыеп, он тарттырып, ипи пешерә. Яңа пешкән ипине оныкларына алып килә һәм үзе дә бераз кабып карый. Әнвәрия эштән кайтканда, балалар инде ипине ашап бетергән була. Ашлык агулы булганмы, әллә башка сәбәпме, бер мизгелдә Әнвәрия әнисен дә, өч баласын да югалта. Иң кадерле кешеләренең дүртесе дә вафат була. 19 яшендә яшь хатын бөтенләй бер ялгызы кала. Озакламый иренең сугышта вафат булуы турында да кара мөһерле хат килә.

...Җаны әрнегән, алга таба ничек яшәргә белмәгән чаклары күп була аның. Биредә барысы да балаларын, әнисен, ирен хәтерләтә... Әлеге ачы югалту хәсрәтен онытыр өчен ул Урта Азиягә китә. Анда да башлангыч сыйныф укытучысы булып эшли. Яңадан, тынгысыз заманнар башлангач, алар туган якларына әйләнеп кайта. Әйе, алар. Чөнки ул алты айлык Әлфияне – апасының кызын тәрбиягә ала һәм аны яратып, җил-яңгыр тидермичә үстерә. Алар гаиләләре белән Алабакүлгә кайтып төпләнә. Бүген Әнвәрия апа гаиләсе белән биредә, якыннарының кайгыртуында һәм җылысында яши. Игътибарлы һәм игелекле булганнары өчен ул аларга бик тә рәхмәтле. Алар шулай карап-тәрбияләп торганга күрә озын гомер кичерәм, ди ул.

Юлия ДӘҮЛӘТБАЕВА.
Ютазы районы

Үзе генә күрә алмады...

Гомерен мәктәптә физика-математика укытуга багышлаган әтием Әхмәт Алишевны да «кара исем» еллар буе эзәрлекләп килде. Мәчетләрне җимергән, манараларын кисеп төшергән шәхес культы елларында әтисе Габделхак мулланы гаепсездән гаепле ясаганнар.

...Бабамны сөргенгә җибәргәч, гаиләсен өйләреннән куып чыгаралар. Барлык мал-мөлкәтләре тартып алынып таратыла. Бабайны сөргенгә озатканда әтием Әхмәткә – биш, абыйсы Заһитка – җиде, сеңлесе Мәрьямгә өч яшь була. Күрше Хмелевка авылының хәлле генә кешесе өйләрен сүтеп алып, күчереп, үзенә өй иткән. Алар мунчада яши башлый. Ашарга ризык, киярге кием юк. Зур әнием Хәдичә, кул арбасы тартып, балаларын утыртып, үзенең туган авылы Әлки районындагы Чуаш Кичүе авылына китә. Кечкенә баласы Мәрьям авыру тиеп үлә. Туган авылында да озак төпләнеп яшәргә мөмкинлек булмый зур әнигә, «халык дошманы» гаиләсен сыендыруга шикләнеп карыйлар. Зур әни, әтиемне шул районның Урта Әлки авылындагы балалары булмаган Әхмәтсабир Исмәгыйлов гаиләсенә асрамага биреп калдырып, арбасын тартып, Заһит улы белән кире Иске Рәҗәпкә әйләнеп кайта. Кайтуларына мунчалары да янган була. Җир казып, землянкада яши башлыйлар. Бераз хәлләнгәч, зур әнием әтиемне кире үз янына алып кайта. Хәер сорашып тамак туйдыралар.

Армия хезмәтеннән, сугыштан (япон сугышыннан) кайткач, әтием Әхмәт читтән торып укытучылыкка укырга урнаша. Кузнечиха райсоветының мәдәният бүлегендә инспектор вазыйфасында эшләп ала. Ике ел колхозда эшли, шул ук вакытта комсомол секретаре эшен дә алып бара. Шулай эшли торгач, хуҗалыкка сыер алуга ирешәләр. Әтием авылның иң чибәр, уңган кызына өйләнә. Өй җиткерү өчен, шул сыерны җигеп, урманнан бүрәнә ташыйлар, бура бурап, бер ызбалы өй җиткерәләр. Укуын тәмамлагач, юллама белән Әлки районы Татар Төгәлбае авылына эшкә җибәрелә. Анда бернечә ел эшләгәч, туган авылына укытучы булып кайта. Эшләү дәверендә һәрвакыт макталып, бик күп мактау кәгазьләре белән бүләкләнде. Алыштыргысыз агитатор, райкомның штаттан тыш пропагандисты, районда беренчеләрдән булып ветераннар (пенсионерлар) оешмасын төзеп, 15 еллап аның рәисе вазыйфасын башкарды. Сугышта үлеп калганнарның тол хатыннарына пенсияләрен юллау, арттыру өчен күп оешмаларга хатлар язды, бик күп кешегә булышты.

Репрессия чорындагы авыр еллар эзсез үтмәгән, сәламәтлеге какшау сәбәпле, бу якты дөньядан әтием иртә китте. Язмышыма төшкән өлештер инде дип, үзен юатып яшәсә дә, кечкенәдән сабый йөрәгенә кереп оялаган куркку хисе белән яшәү үзенекен итте. Шулай да күңел төшенкелегенә бирелмәде, укыды, тырышып эшләде. Ярты гасыр буена тартырга туры килгән нахакка җәберләнүнең аяусыз авырлыгын үз башыннан кичергәннәр генә аңлыйдыр. Озак еллар кимсетелеп, куркып яшәгән бер зат башыннан үткәннәрен язсаң, вакыт та, көч тә җитәсе түгел. Күпме еллар узган, күпме буыннар алмашынган, ә ул еллар кайтавазы әле һаман да яңгырый. Бабамның, әтиемнең язмышы мине тетрәндерә... Әмма үз көчләре, үз хезмәтләре белән гомер кичерүче, дәреслекне яратучы тырыш Алишлар нәселе дәвам итә, яши!

ТАССР прокуратурасының 1989 ел, 29 май карары нигезендә бабам Габделхак Нурулла улы Алишев акланды. Керсез исеме, даны кире кайтарылды. Тик моннан ни файда үзләре һәм балалары үлеп беткәч?! Инде оныклары да олы яшьтә. Билгеле ки, без, оныклары, куану хисе кичердек, бабабызның аклануын канәгатьләнү белән кабул иттек. Юк, гаепле булмаган бабам! Моны дәлилләү документы кулымда. Ни кызганыч, әтием бу документларны күрмичә үлеп китте, шуңа йөрәгем әрни.

Репрессия еллары, хәзерге һәм киләчәк буыннар өчен сабак булып, халык хәтерендә мәңге сакланырга тиеш. Мондый явызлык безнең җәмгыятьтә башка беркайчан да булмасын, хаталар ясалмасын, золымнар кабатланмасын иде.

Флёра ХӘЙРЕТДИНОВА,
Спас районы Иске Рәҗәп авылының ветераннар (пенсионерлар) оешмасы рәисе

76 елдан соң – медаль

Без инде Бөек Җиңүнең 76 еллыгын билгеләп үттек, ә сугыш үзе турында искә төшерүен дәвам итә. Медальләр һәм орденнар үз геройларын таба тора. Хәзер аларны фронтовикларның балалары, оныклары, туганнары ала. Чөнки солдатлар үзләре исән түгел инде.

Әлмәттә яшәүче Людмила Даниловна Березова өчен зур вакыйга булды. Район башлыгы Тимур Нагуманов аңа бертуган абыйсы Георгий Данилович Зверевның дәүләт бүләге – «Батырлык өчен» медален тапшырды. Георгий Зверевның гомере 1943 елда өзелә.

Людмила Даниловна үзе дә сугыш елларында армия сафларында хезмәт итә.

– Мин анда 4 ел 2 ай һәм 19 көн булдым. Сугыш авырлыкларын кичердем, әмма тормыш сөюемне югалтмадым, – ди Людмила Даниловна.

«УФАЛЛА» АРБАЛАРЫ

Мин күп еллар китапханәдә эшләгәнлектән, халык белән төрле чаралар үткәрәм. Бөек Ватан сугышы ветераннарын, җиңү яулап кайтып, ару-талуны белмичә, авыр елларда тәмам бөлгән авылларны торгызышып, балалар үстереп бакыйлыкка күчкән ватан уларын, сугыш ятимнәрен, тыл ветераннарын барлау өчен, төрле гаиләләрдә булып, гаиләдә саклана торган кадерле истәлекләрне күреп, сугыш ятимнәренең моң-сагышларын тыңлап, алар турында тарихи истәлекләр язып калдырам.

Күзкәй авылында үсмер чакларында ук фермага килеп, гомерләре буе терлекчелектә эшләгән Ләбүдә белән Мөсфирә Хуҗиәхмәт кызлары яши. Әтиләре беренче көннәрдән үк сугышка киткән. Әниләре Хәнифә берсеннән-берсе кечкенә 5 бала белән калган. Мин аларга фронттан әтиләреннән килгән хатлар белән танышырга, истәлекләрен барларга дип кердем. Хәерле булсын, авыр хатирәләрен кузгаттым. Сүз булсын өчен түгел, шундый авырлыклар белән яуланган бүгенге тормышыбызның кадерен белик, илкөнебезне кулдан килгәнчә имин, матур итик, иҗтиһат итеп яшик, дип язам.

– Әтинең төсен дә хәтерләмибез инде. Беренче айларда әнигә өметле генә хатлар язган. Без укый торган түгел – гарәпчә язылган. Күпмедер вакыттан соң хат килү тукталды. Аннары өй тулы балаларның өметен сүндереп, үлгән хәбәре килде, – дип сөйләп китте Ләбүдә апа. – Мунча хәтле генә өй, әти өй салырга ниятләп йөргәндә башланган сугыш. Сәкедә тезелешеп йоклыйбыз. Әнине бик сирәк күрә идек. Таңнан эшкә чыгып китә, караңгыда гына егылырдай булып арып кайта. Көндезләрен әби килеп, күз-колак була, эш куша. Кесәсендә пешкән зур бер бәрәңге булыр иде, аны бишебезгә тигезләп бүлә. Кышын өй салкын, ягарга утын юк. Яз җитүгә, апалар басуга өшегән бәрәңге җыярга баралар. Аны чи килеш төеп, мичтә яисә учакта кыздырып ашыйбыз. Җәй көне бераз рәхәткә чыгабыз: башта кычыткан, аннары балтырган, алабута, чүгендер яфрагы ашыйбыз. Без – балаларга ярый әле, гаилә башы, таянырга терәге булмагач, әнигә бик авыр булды. Шулай бер елны, салымыгыз түләнеп бетмәгән дип, сыерны алып чыгып киттеләр. Биш бала – барыбыз да кычкырып елыйбыз. Шул малкай аркасында җан асрыйбыз бит. Җәүдәт абыебыз, ничек кирәк алай, сыерны ычкындырып җибәрде. Ләкин алырга килгән кешеләр, тотып, малкайны Калмия кешесенә сатканнар дип ишеттелдә. Әнкәебез җыбегән хатын түгел иде – бөтен документларны җыеп, әтинең сугышта үлүе турындагы хатны да алып, Минзәләгә китте (район үзәге шунда иде). Аннан: «Хөкүмәткә юкка рәнҗегәнмен, сыерны алып чыгып китәргә тиеш булмаганнар», – дип кайтты. «Недоимка»ны каплап, әнигә калган акчасын биргәннәр. Шул суммага бик матур кызыл бозау, кәҗә сатып алдык. Башта кәҗә сөте эчеп җан асрадык, аннары бозау үсеп җитте, сыерлы булдык. Әле бит калган түләүләр дә хәттин ашкан: хөкүмәткә 40 килограмм ит, 250 литр сөт, йомырка, 3 центнер бәрәңге тапшырырга кирәк. Сеңлем Мөсфирә белән әнине искә алып, аның чыдамлыгына хәйраннар калабыз. Кайлардан көч алды икән, иренең кайтасы юк, өмет өзелгән, балалар дип тырышкан инде бахыр. Колхоз эшенә карусыз иде: тавыклар карады. Йомыркаларын каргалар алмасын дип, без дә көннәр буе шунда урала идек. Аннары ул сарык карады. Аларны бәрәнләтеп, бәтиен имезеп, иртәнге якта сарыкларын савып,

көтүгә алып чыгып китәбез. Әнине ял иттерәбез дип, Кычыткан чокырында сарык көтәбез. Аннары әни безне колхоз басуына иартеп йөри башлады, чүп утыйбыз, урак урырга өйрәндек. Без утап җыйган үләнне әниләр «уфалла» арбасы белән тартып кайталар. Без хәлдән килгәнчә, арттан этәбез. Сыерга кышлык азыкны шулай әзерлибез.

Мөсфирә апа анда-санда гына сүз кыстыра. Ләбүдә апаның хәтере яхшы, аннары ул олырак та булган бит.

– Бүгенге кеше ышанмаска да мөмкин, – дип дәвам итә ул. – Колхоз сарык асрагач, бер заман районның хәзерләүләр конторасыннан сарык сөте тапшырырга язу килде… Без күргәннәрне сөйләп бетерә торган түгел. Сугыш беткәч тә, җиңеллек сизмәдек. Ачлыгына түзәргә дә, ризык юнәтергә дә өйрәндек, ә менә әтиле буласы килә, берни эшләр хәл юк. Үлгән хәбәре килсә дә, өмет сүнмәде. Күктә самолет күргән саен, капка башына менеп, бар көчемә: «Әтине алып кайт!» – дип кычкыра идем. Абзарга кереп, кеше күрмәгәндә иплләп кенә «әти» дип дәшеп карыйм. Үзәкләрне өзде ул ятимлек.

Сугыш ятимнәренә бераз пособие бирә башлаганнар. Хәнифә апа аны, балаларның авызыннан өзеп, заемга илтеп түли торган булган. Сугыш чорында тәмам күтәрәмгә калган колхозда да халыкны ашатырлык ризык юк. Колхозчылар, көнне төнгә ялгап, «таяк»ка эшли.

– Ярый әле Җәүдәт абый атлы эшкә йөри башлады. Әни шунлыктан бераз тын алды, – дип сүзгә кушыла Мөсфирә апа. – Бер җәйдә колынлы бияне төнгә чирәмгә арканлагач, колынын бүре буган. Күрше-тирәләр белән бергә аны суеп, итен ашадык. Әни колын өчен бозау түләде.

– Ул чорның авырлыгын сөйләп бетерә торган түгел, – дип дәвам итә Ләбүдә апа Гыймазиева. – Безне, буй җиткереп килә торган кызларны, Лаешка урман кисәргә җибәрделәр. Мәсүфә, Сәмигалар белән су басарга тиешле болынны агачлардан чистарттык. Чатнама салкыннарда баракта яшәдек, көнлек норманы бирәләр, шуны үтәмичә эш урыныннан китмисең, тамагың тукмы, дип сораган кеше юк. Урман кисүдән кайттың да ял иттең дигән сүз түгел бит әле, тагын да ераккарак – Мәскәүдән 200 чакрымдагы Калининград өлкәсендә торф чыгардык. Торф җире агач белән капланган. Башта аларны кисеп, трактор арбаларына төяп җибәрәбез. Агач тамырын трактор кубара, без төбен чистартабыз. Шул урыннан торф чыгарып, май белән бутап, брикет ясыйбыз. Авылдан 8–9 кыз эшләдек. И-и, ул авылны сагынулар! Бик яшь идек бит әле…

Аннары – колхозның терлекчелек фермасы. Мөсфирә дә, Ләбүдә апасына ияреп, сыер саварга килә. Һәм шушы авыр хезмәткә алар 30–40 ел гомерләрен багышлыйлар.

– Зарлануым түгел, – ди Ләбүдә апа, – ни хәл итәсең, яшьлегебез сугыш чорына туры килде, ил белән күтәрдек ул авырлыкны. Тик менә илебезнең иңнәре тураеп, 77 ел тыныч тормышта яшәсә дә, сугыш ятимнәренә, үсмер чакларында ук тормыш тәртәсенә җигелгән буын кешеләренә һаман да игътибар юк. Габделфәт Сафинның «Уфалла арбасы» җырын тыныч күңел белән тыңлый алмыйм. Ул җыр – сугыш чоры балалары язмышы…

Үземә дә читен булып китте. Бүгенге тормыштан канәгать булып, Ходайга шөкер итеп яшәп ятучы Ләбүдә, Мөсфирә апаларның күңел сандыгындагы хатирәләрен кузгаттым. Кичерә күрсеннәр, ә без сугыш чоры балаларының яшәү, хезмәт батырлыгын онытмасак иде.

Тәнзилә ШӘЙХНУРОВА.
Тукай районы Күзкәй авылы

Шигърият

Фирдәүсә БИКМӘТОВА

ҖИРНЕ БИЗӘРЛЕК

Гомер итик, әйдә, ду китереп,
Тойгыларны тормыйк иярләп.
Тел шартлатып, көнләшерлек итеп,
Вәт яшәде җирдә диярлек!

Дөнья күген кочып хыял йөрсен,
Җайсыз кысалардан бушанып.
Киләчәкне барлап уй йөгерсен,
Үткән тормышыңнан хушланып.

Хәйран калып яшә бу тормышка,
Хисләреңне куеп иркенгә.
Җәүһәр итеп кабыз тормышыңны,
Яктылыгы җитсен һәркемгә.

Яхшылык кыл җирдә, булсын атың,
Чикләр белми илләр гизәрлек.
Кеше сокланырлык гамәлләр кыл,
Үзең белән җирне бизәрлек.

СУКМАК

Юл башында тормышың киң, иркен.
Сыйдырырга дөньялыкны колачың тар.
Киртәләрне җимереп атлар өчен,
Гомер җитмәс изге максатың бар.
Мал барларга, дан яуларга әйдәп,
Җилкендереп торган сөйгәнең бар.
Күкрәк киереп, текә йөргән чакта,
Диңгезләр сай әле, галәмнәр тар.
Аяк терәп җирдә яшәгәндә,
Сынауларны җиңеләйтер
дусларың бар.
Бу дөньяны хозурланып кочар өчен,
Сөяр өчен яшьләй колачың тар.
Гомер кичә-кичә йөрәк тала.
Ипи бүлгән дуслар читтә кала.
Борылышларда киң юл, аһ, тарая.
Күпләр белән ара ерагая.
Онытылмас үткен еллар кала,
хәтер кала,
җырлар кала,
уйлар кала.
Бакыйлыкка ялгыз атлар өчен
сукмак кала…
Сукмак кала…
Сукмак кына!!!

БҮГЕН ЯШӘ ИКӘН!

Гомер дигән биек тауга карап,
Менгән чакта йөрәк тала икән.
Дәрт булса да, дәрман саекканда,
Тау башында хыял яна икән.

Таулар түбәсендә кылдай хыял,
Чыңлап өзелгәндә упкын икән.
Киләчәкне уйлап юл барганда,
Яшәү ямен таты бүген икән!

Хатирәләр күлен кичкән чакта,
Узган гомер артка дәшә икән.
Томан сарган күлгә керми генә,
Бүген яшә, бүген яшә икән!!

ЙӨРӘК

Язгы ямьнәр көтеп тибә иде,
Тынгы җуйды бу арада йөрәк.
Дерт итә дә сикерә дә куя.
Ул җанкайга әллә нәрсә кирәк?

Нинди хәтәр көтә бүген йөрәк,
Әйтерсең лә терәп ук аталар…
Язны көткән җирне дерелдәтеп,
Дары исе чәчеп туп аталар.

Туп аталар гөрселдәтеп җирне.
Кемнең җанын ялмап ялкын өтә?
Сүнгән йөрәкләргә каршы йөрәк,
Аһ, итә дә, сискәнә дә китә.

Файдалы киңәшләр

ШИФАЛЫ КАТНАШМА

Бавырны, эчәклекне чистартырга, иммунитетны күтәрергә теләсәгез, ярты стакан лимон согы, 200 грамм бал, 2 аш кашыгы зәйтүн маен әйбәтләп болгатып ясалган катнашманы иртән ач карынга 1 чәй кашыгы эчегез.

vk.com

ОЕКБАШ ЭЧЕНӘ – СУГАН

Суганның файдасы күп: ул борын тыгылу, төрле ялкынсынуны, үлекле шешләрне, колак һәм теш сызлаганны дәвалый. Иң кызыгы шунда: оекбаш эченә суган тыгып йокласаң, югары температуралы суык тиюдән дә котылып була икән. Әлеге ысулны кулланып карарга теләсәгез, калын итеп, бөҗралап туралган башлы суганны табаныгызга куегыз да азыктөлек пленкасы белән чорнагыз. Аннан аякларыгызга оекбаш киегез һәм аларны биеккәрәк – мендәр өстенә куеп йоклагыз. Төн буена суган канны чистартачак, бактерия һәм микробларны үтерәчәк.

vk.com

vk.com

БУЫННАР СЫЗЛАВЫН КӨЛ ДӘВАЛЫЙ

Җиләк-җимеш агачларын кисәргә туры килгән очракта, аларны яндырыгыз, чөнки көле бик файдалы. Җылы көлне буыннарга ышкырга һәм ике сәгатькә бәйләп куярга кирәк. Соңыннан әлеге урынны сөртәсе һәм юасы түгел. Берничә көн шулай эшләргә киңәш ителә.



Нияз Бишбалта

ҖАВАПЛАР. Горизонталь буенча: юлбарыс, усак, кына, команда, алу, кич, бу, чак, банкомат, жанр, ип, сәлаусен.
Вертикаль буенча: юртак, күб, божан, ука, мәче, көрпә, сумка, чит, баян, лама, агу, керосин.

ИММУН СИСТЕМАСЫН НЫГЫТЫРГА ЯРДӘМ ИТҮЧЕ РИЗЫКЛАР


vk.com

Йомырка

➢Йомырка – туклыклы һәм файдалы ризыкларның берсе. Ул бик күп витаминнар, минераллар һәм аминокислоталар һәм минималь калория белән аерылып тора. Ләкин барлык йомырка да бер үк төрле түгел. Әлбәттә, фермер йомыркаларын гадәти кибет йомыркалары белән чагыштырсаң, фермерныкы микроэлементларга бай, сәламәт иммун системасын сакларга булыша. Аларда Д витамины, Е һәм B_{12} витаминнары күбрәк.

vk.com

Болгар борычы

➢Татлы борычның төрле төсләрдә булуының сәбәбе бар: төсе – борычның авыруларга каршы торучы антиоксидантларга бай булуын күрсәтүче билге. Болгар борычы бета-каротин кебек көчле антиоксидантларга гына түгел, С витаминына да бик бай. Анда С витамины хәтта әфлисундагыдан да күбрәк.

vk.com

Сарымсак

➢Сарымсакта аллиин бар. Бу антиоксидант иммун системасын ныгытырга ярдәм итә. Максималь файда һәм антиоксидант эффектлары алу өчен, бик күп чи сарымсак кирәк түгел һәм аны башка ризыкка кушып ашарга да мөмкин.

Белгечләр кыздырылган сарымсакны йомырка омлетына өстәмә итеп куллану икеләтә файдалы дигән фикердә.

vk.com

Көнбагыш орлыклары

➢Сез чистартылганын яратасызмы, әллә инде кабыгы белән сатып алып чиртәсезме – аерма юк. Көнбагыш орлыклары куллану – сезнең иммун системагызны көчәйтүнең иң җиңел ысулы. Купчелек орлыклар кебек, алар ялкынсынуга каршы торучы майларга, иммунитет нигезе булган ак кан күзәнәкләрен активлаштыра һәм зарарланган күзәнәкләрне яңарта торган Е витаминына бай.

Кефир

➢Кефир пробиотиклар белән тулы. Пробиотиклар – файдалы бактерияләр һәм гөмбәчекләр, ашказаны-эчәк трактындагы тере биокультуралар. Алар эчәк микрофлорасының туклыклы матдәләр үзләштерүе өчен һәм организмга инфекциягә каршы торырга ярдәм итә торган кушылмалар җитештерү өчен җаваплы.

◆Сәламәтлеккә зыяны булырга мөмкин. Алдан табиб белән киңәшләшегез.

ТАТАРСТАН ВЕТЕРАНЫ
Республика ветераннары (пенсионерлары) төбәк иҗтимагый оешмасы советы һәм «Ватаным Татарстан» газетасының уртак кушымтасы.
Чыгарылыш өчен җаваплы – **Гөлгенә ШИҺАПОВА**. Биткә салучы һәм бизәүче – **Рөстәм МИҢНУЛЛИН**.
Безнең адрес: Казан шәһәре, Театр урамы, 5 й.
Телефон: 8(843) 238-16-88
Электрон адрес: soovp.kzn@tatar.ru